**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«30» 03 2020 ел № 4

Татарстан Республикасы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан махсус инвестиция контрактларын төзү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» 2014 елның 31 декабрендәге 488-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 4 өлеше нигезендә Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Расларга:

1.1. Татарстан Республикасы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан махсус инвестиция контрактларын төзү тәртибен 1 нче кушымта нигезендә.

1.2. Инвесторның махсус инвестиция контрактын төзү турында гариза формасын 2 нче кушымта нигезендә.

1.3. Махсус инвестиция контрактларын төзү мөмкинлеген бәяләү буенча ведомствоара комиссия эшчәнлеген формалаштыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Б.В.Башкарма комитет Җитәкчесе В.А.Валиева

Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның ___ ____________ ____ номерлы карарына кушымта

## Татарстан Республикасы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан махсус инвестиция контрактларын төзү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан махсус инвестиция контрактларын төзүнең әлеге тәртибе (алга таба - тәртип) Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан махсус инвестиция контрактларын төзү механизмын билгели, Россия Федерациясе һәм (яки) Татарстан Республикасы катнашында төзелә торган махсус инвестиция контрактларыннан тыш.

2. Махсус инвестиция контракты Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге (алга таба – Бәтке авыл җирлеге) Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) исеменнән Бәтке авыл җирлеге территориясендә махсус инвестиция контрактында каралган срокта үз көче белән яисә башка затларны җәлеп итеп яңа сәнәгать производствосын төзү яисә модернизацияләү һәм (яки) үзләштерү йөкләмәсен үз өстенә алган юридик зат яисә шәхси эшмәкәр (алга таба - инвестор, җәлеп ителгән зат, инвестиция проекты) белән төзелә.

Махсус инвестиция контракты алар кысаларында инвестиция проектлары гамәлгә ашырылган Бәтке авыл җирлеге муниципаль программаларының максатчан күрсәткечләренә һәм индикаторларына ирешү максатында төзелә.

3. Махсус инвестиция контракты 5 елга арттырылган, ләкин 10 елдан да артмаган инвестиция проектының бизнес-планы нигезендә инвестиция проектының проект операция табышына чыгу вакытына тигез срокта төзелә.

4. Инвестор махсус инвестиция контрактын төзү өчен, Башкарма комитет карары белән расланган форма буенча түбәндәгеләрне теркәп, Башкарма комитетка гариза бирә:

а) инвестиция проектына инвестицияләр кертүне раслаучы документларның (кредит шартнамәсе яки инвестиция проектын финанслау белән башлангыч кредит шартнамәсе яки җәлеп итела торган инвестицияләр күләмен раслый торган башка документлар) күчермәләре һәм инвестиция проектын гамәлгә ашыру барышында кимендә 10 яңа эш урыны булдыру һәм махсус инвестиция контракты срогы тәмамланганчы саклап калу турында язма гарантия йөкләмәсе;

б) муниципаль хокукый актларда каралган чаралардан инвестор махсус инвестиция контрактына кертергә тәкъдим итә торган сәнәгать өлкәсендә эшчәнлекне стимуллаштыру чаралары исемлеге;

в) инвестор һәм (яисә) җәлеп ителгән зат йөкләмәләренең (җәлеп ителгән очракта) исемлеге;

г) түбәндәге мәгълүматларны:

- производствосы махсус инвестиция контрактын үтәү барышында төзелә яки модернизацияләнә һәм (яки) үзләштерелә торган сәнәгать продукциясенең характеристикалары турында;

- инвестиция проекты чаралары исемлеге турында;

- инвестиция проектына инвестицияләр күләме турында;

- инвестиция проектын гамәлгә ашыру барышында ирешелергә тиешле нәтиҗәләр (күрсәткечләр) турында (еллык һәм йомгаклау күрсәткечләре), шул исәптән түбәндәгеләрне кертеп:

- җитештерелгән һәм сатылган продукция күләме (акчалата чагылышта) (ел саен календарь ел ахырына һәм махсус инвестиция контрактының срогы тәмамлануга);

- махсус инвестиция контракты срогы тәмамланганнан соң, түләүгә планлаштырылган салымнар күләме;

- махсус инвестиция контракты срогы тәмамлануга чыгарыла торган сәнәгать продукциясе бәясендә кулланыла торган материаллар һәм чит ил компонентлары (җиһазлары) бәясе өлеше;

- инвестиция проектын гамәлгә ашыру барышында булдырыла торган эш урыннары саны;

- инвестор тарафыннан кабул ителгән йөкләмәләрне үтәүне характерлаучы башка күрсәткечләр.

Махсус инвестиция контрактын төзүдә җәлеп ителгән зат катнашкан очракта, әлеге пунктта күрсәтелгән гариза шулай ук җәлеп ителгән зат тарафыннан имзаланырга тиеш.

5. Сәнәгать продукциясе производствосы төзелә яисә модернизацияләнә торган махсус инвестиция контрактын төзү өчен, инвестор әлеге тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документлар белән тапшырыла торган гариза составында сәнәгать производствосын төзүне яки модернизацияләүне һәм эш урыннарын булдыруны, булдырылган (модернизацияләнгән) егәрлекләрдә сәнәгать продукциясен эшләп чыгаруны үзләштерүне һәм инвестиция характерындагы түбәндәге чыгымнарны мәҗбүри рәвештә гамәлгә ашыруны раслый торган документлар тапшыра:

а) яңа җитештерү егәрлекләрен булдыру өчен, җир кишәрлекләрен сатып алуга яки озак вакытка арендага алуга (инвестиция проекты гамәлгә ашырыла торган җир кишәрлеге инвестор яки җәлеп ителгән затлар милкендә булган очраклардан тыш);

б) проект документларын эшләүгә;

в) җитештерү биналарын һәм корылмаларын төзүгә яки реконструкцияләүгә;

г) төп средстволарны сатып алуга, коруга, җитештерүгә, китерүгә, расконсервацияләүгә һәм модернизацияләүгә (инвестиция проектын гамәлгә ашыру барышында сатып алына торган җиһазларның минималь өлеше модернизацияләнә һәм (яки) расконсервацияләнә торган җиһаз бәясенең кимендә 25 процентын тәшкил итә), шул исәптән таможня пошлиналарына һәм таможня җыемнарына, шулай ук төзелеш-монтаж һәм эшләтеп җибәрү-көйләү эшләренә.

6. Әлеге тәртипнең 5 пунктында каралган раслаучы документлар булып инвестиция проектының бизнес-планы, инвестиция проектын гамәлгә ашыруда

өченче затларның катнашу тәртибен билгели (булганда) торган инвестиция килешүе (килешүләре) яисә инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында алдан шартнамә (шартнамәләр) күчермәсе тора.

7. Россия Федерациясендә җитештерелгән аналоглары булмаган сәнәгать продукциясенә кертелгән сәнәгать продукциясе производствосы үзләштерелә торган махсус инвестиция контрактын төзү өчен, инвестор әлеге тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документлар белән гариза составында инвестиция проектын гамәлгә ашыру барышында Россия Федерациясендә җитештерелгән аналоглары булмаган сәнәгать продукциясе производствосы үзләштерелүен раслаучы документлар һәм инвестиция килешүе (килешүләре) яки инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында алдан килешү (килешүләр) күчермәсе (булганда) тапшыра.

8. Башкарма комитет әлеге Тәртипнең 4-8 пунктларында күрсәтелгән документлар кергән көннән алып 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, аларны инвестор гаризасының һәм бирелгән документларның әлеге тәртипнең 4-7 пунктларына туры килүе турында Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе кул куйган башлангыч бәяләмә белән махсус инвестиция контрактларын төзү мөмкинлеген бәяләү буенча ведомствоара комиссиягә (алга таба - комиссия) карау өчен җибәрә.

Бәяләмәне әзерләү тәртибе Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә.

9. Махсус инвестиция контрактларын төзү мөмкинлеген бәяләү буенча ведомствоара комиссия турында Башкарма комитет тарафыннан расланган нигезләмәгә таянып эш итүче комиссия инвестор тәкъдим иткән шартларда махсус инвестиция контрактын төзү мөмкинлеге (мөмкин булмавы) турында бәяләмә әзерли.

10. Әлеге тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән бәяләмәне әзерләгәндә, комиссия инвесторның һәм (яки) җәлеп ителгән затның әлеге тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән инвестор тәкъдим иткән инвестиция проектының характеристикаларына үзгәрешләр кертергә хокуклы түгел.

11. Комиссия әлеге тәртипнең 4-7 пунктларында күрсәтелгән документлар Башкарма комитетка кергән көннән алып 60 эш көненнән дә соңга калмыйча, Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенә түбәндәгеләрне үз эченә алган бәяләмәне җибәрә:

а) инвестор һәм җәлеп ителгән затның исеме (җәлеп ителгән очракта);

б) яңа сәнәгать производствосын төзү һәм (яки) үзләштерү буенча инвестиция проектының исеме;

в) инвесторга һәм (яки) җәлеп ителгән затка (җәлеп ителгән очракта) карата гамәлгә ашырыла торган кызыксындыру чаралары исемлеге ;

г) инвестор һәм җәлеп ителгән зат (җәлеп ителгән очракта) йөкләмәләре исемлеге;

д) махсус инвестиция контрактының гамәлдә булу срогы;

и) инвестиция проектын гамәлгә ашыру барышында ирешелергә тиешле нәтиҗәләр һәм күрсәтелгән нәтиҗәләрне үлчәү күрсәткечләре (еллык һәм йомгаклау күрсәткечләре);

к) махсус инвестиция контрактын үтәү барышында производствосы төзелә яки модернизацияләнә һәм (яки) үзләштерелә торган сәнәгать продукциясе характеристикалары;

л) инвестиция проекты чаралары исемлеге;

- инвестиция проектына инвестицияләр күләме;

н) инвестор тәкъдим иткән шартларда махсус инвестиция контрактын төзү мөмкинлеге (мөмкин булмавы) турында комиссия карары.

12. Комиссия түбәндәге очракларда махсус инвестиция контрактын төзү мөмкин булмау турында карарны үз эченә алган бәяләмәне җибәрә:

а) инвестиция проекты әлеге тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга туры килми;

б) инвестор тарафыннан тапшырылган гариза һәм документлар әлеге тәртипнең 4-8 пунктларына туры килми;

в) инвестор гаризасында күрсәтелгән инвестор һәм (яки) җәлеп ителгән затка карата тәкъдим ителгән кызыксындыру чараларының берсе дә муниципаль хокукый актларга туры килми.

14. Комиссия бәяләмәсе Башкарма комитет тарафыннан кабул ителгән көннән соң 10 эш көне эчендә махсус инвестиция контрактын төзүдә катнашучы затларга җибәрелә.

Махсус инвестиция контрактын төзү мөмкинлеге турында карарны үз эченә алган бәяләмә җибәрелгән очракта, Башкарма комитет мондый бәяләмә белән бер үк вакытта инвесторга һәм җәлеп ителгән затка (җәлеп ителгән очракта) комиссия бәяләмәсен исәпкә алып, инвестор һәм җәлеп ителгән зат (җәлеп ителгән очракта) йөкләмәләре исемлеген үз эченә алган махсус инвестиция контракты проектын җибәрә.

15. Инвестор һәм җәлеп ителгән зат (җәлеп ителгән очракта), махсус инвестиция контракты проекты алынганнан соң, 10 эш көне эчендә Башкарма комитетка имзаланган махсус инвестицин контрактын, яисә инвесторның яки җәлеп ителгән затның (җәлеп ителгән очракта) язма рәвештә рәсмиләштерелгән махсус инвестиция контрактына кул куюдан баш тартуын, яисә каршылыклар беркетмәсен (бәяләмәмдә булган махсус инвестиция контракты шартларына кагылмаган мәсьәләләр буенча) җибәрә.

16. Каршылыклар беркетмәсе алынганнан соң, 10 эш көне дәвамында Башкарма комитет инвестор яки җәлеп ителгән зат (җәлеп ителгән очракта) белән мондый каршылыкларны җайга салу, махсус инвестиция контрактына кул кую яисә инвестор яки җәлеп ителгән зат (җәлеп ителгән очракта) махсус инвестиция контрактына кул куюдан баш тарту өчен сөйләшүләр алып бара.

17. Башкарма комитет инвесторга һәм җәлеп ителгән затка (җәлеп ителгән очракта) махсус инвестиция контрактын төзү мөмкинлеге турында карарны үз эченә алган бәяләмәне җибәргәннән соң, 20 эш көне эчендә инвестор һәм җәлеп ителгән зат (җәлеп ителгән очракта) тарафыннан имзаланган махсус инвестиция контракты проектын, яисә каршылыклар беркетмәсен, яисә махсус инвестиция контрактын имзалаудан баш тартуны алмаган очракта, инвестор яки җәлеп ителгән зат (җәлеп ителгән очракта) махсус инвестиция контрактын имзалаудан баш тарткан дип санала.

18. Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе инвестор яки җәлеп ителгән зат (җәлеп ителгән очракта) тарафыннан имзаланган махсус инвестиция контрактын алган көннән соң 10 эш көне эчендә махсус инвестиция контрактына кул куя.

19. Махсус инвестиция контракында катнашучыларның барысы да кул куйган нөсхәләр Башкарма комитет тарафыннан махсус инвестиция контрактында катнашучыларга тапшырыла.

Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 12 мартындагы 1 нче номерлы карарына кушымта

# Махсус инвестиция контрактларын төзү мөмкинлеген бәяләү буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә

1. Әлеге нигезләмә махсус инвестиция контрактларын төзү мөмкинлеген бәяләү буенча ведомствоара комиссия (алга таба – комиссия) эшчәнлеген формалаштыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен билгели.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте актларына, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Хөкүмәте актларына, муниципаль хокукый актларга таяна.

3. Комиссия комиссия рәисе, аның урынбасары һәм комиссия әгъзалары составында төзелә.

4. Комиссия составына керә:

а) комиссия рәисе – Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе;

б) комиссия рәисе урынбасары – Бәтке авыл җирлегенең әйдәп баручы белгече;

в) 1 комиссия әгъзасы - ________________________ (килешү буенча).

г) 2 комиссия әгъзасы – Бәтке авыл җирлеге Советы депутатлары (килешү буенча).

5. Комиссия составы Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе күрсәтмәсе белән раслана.

6. Комиссия эшенә рәис карары буенча, аның һәр конкрет утырышында катнашу өчен, кызыксынучы җирле үзидарә органнары һәм оешмалар вәкилләре тавыш бирү хокукы белән (алга таба – тавыш бирү хокукына ия катнашучылар) җәлеп ителергә мөмкин:

а) сәнәгать өлкәсендә эшчәнлек субъектлары һәм шул ук тармакның (аның кысаларында махсус инвестиция контракты төзелә) сәнәгать өлкәсендә эшчәнлеккә ярдәм итү инфраструктурасы оешмалары вәкилләре (5 әгъза) - инвестиция проекты кысаларында производствосы үзләштереләчәк сәнәгать продукциясенең Россия Федерациясендә җитештерелгән аналоглары булмавы турында документы булмаган сәнәгать продукциясе производствосын төзүне яисә модернизацияләүне һәм (яки) үзләштерүне күздә тоткан махсус инвестиция контрактын төзү очрагында.

7. Комиссия рәисе:

а) комиссия эшен оештыра;

б) комиссия утырышларында карау өчен мәсьәләләр исемлеген, срокларын һәм тәртибен билгели;

в) комиссия эшен планлаштыруны оештыра;

г) комиссияне җирле үзидарә органнары һәм оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләрдә тәкъдим итә;

д) комиссиянең һәр конкрет утырышында катнашу өчен тавыш бирү хокукына ия катнашучылар исемлеген раслый.

8. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.

9. Үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен комиссия хокуклы:

а) үз компетенциясенә керүче мәсьәләләр буенча тиешле җирле үзидарә органнары һәм оешмалар белән хезмәттәшлек итәргә, алардан билгеләнгән тәртиптә кирәкле материаллар һәм мәгълүмат алырга;

б) аналитик һәм эксперт эшләрен гамәлгә ашыру өчен экспертларны: фәнни оешмалар вәкилләрен һәм инженер-техник профиль белгечләрен түләүсез җәлеп итәргә, алар комиссия карарларын кабул итүдә һәм тавыш бирүдә катнашмыйлар.

10. Комиссия утырышларын чакыруны һәм үткәрүне вәкаләтле орган елга кимендә ике тапкыр (махсус инвестиция контрактларын төзү турында гаризалар булганда) тәэмин итә.

11. Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, карарлар кабул итү өчен хокуклы дип санала.

12. Комиссия утырышы турында хәбәрнамә һәм кирәкле материаллар комиссия рәисе кушуы буенча вәкаләтле орган тарафыннан аның әгъзаларына һәм тавыш бирү хокукына ия катнашучыларга комиссия утырышын уздырырга бер ай кала җибәрелә.

13. Комиссия әгъзалары һәм тавыш бирү хокукына ия катнашучылар комиссия утырышларында карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышканда тигез хокукларга ия.

14. Комиссия карары утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының һәм тавыш бирү хокукына ия катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән, утырышта катнашмаучы комиссия әгъзаларының һәм тавыш бирү хокукына ия катнашучыларның язма фикерләрен исәпкә алып кабул ителә.

Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

15. Комиссия әгъзалары һәм тавыш бирү хокукына ия катнашучылар конкрет махсус инвестиция контрактына карата мәсьәләләрне караганда, Россия Федерациясе законнары нигезендә инвесторга һәм (яки) җәлеп ителгән затка йогынты ясарга мөмкин дип табылган очракта, үзләре тавыш бирүдән баш тартырга тиеш.

16. Материалларны карау һәм фикер алышу нәтиҗәләре буенча комиссия тарафыннан махсус инвестиция контрактын төзү мөмкинлеге (мөмкин булмавы) турында комиссия бәяләмәсен әзерләү турында карар кабул ителә.

17. Инвестор тәкъдим иткән шартларда махсус инвестиция контрактын төзү мөмкинлеге (мөмкин булмавы) турында комиссия бәяләмәсе түбәндәге мәгълүматларны үз эченә ала:

в) инвесторга һәм (яки) җәлеп ителгән затка (җәлеп ителгән очракта) карата гамәлгә ашырыла торган кызыксындыру чаралары исемлеге;

г) инвестор һәм җәлеп ителгән зат (җәлеп ителгән очракта) йөкләмәләре исемлеге;

д) махсус инвестиция контрактының гамәлдә булу срогы;

и) инвестиция проектын гамәлгә ашыру барышында ирешелергә тиешле нәтиҗәләр һәм күрсәтелгән нәтиҗәләрне үлчәү күрсәткечләре (еллык һәм йомгаклау күрсәткечләре);

к) махсус инвестиция контрактын үтәү барышында производствосы төзелә яки модернизацияләнә һәм (яки) үзләштерелә торган сәнәгать продукциясе характеристикалары;

л) инвестиция проекты чаралары исемлеге;

ж) инвестиция проектына инвестицияләр күләме;

з) инвестор тәкъдим иткән шартларда махсус инвестиция контрактын төзү мөмкинлеге (мөмкин булмавы) турында комиссия карары.

18. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул комиссия утырышында катнашучы барлык комиссия әгъзалары (тавыш бирү хокукына ия катнашучылар) тарафыннан имзалана. Утырышта катнашмаган комиссия әгъзалары (тавыш бирү хокукына ия катнашучылар) тарафыннан бирелгән язма фикерләр беркетмәгә теркәлә.

19. Комиссия эшчәнлеген мәгълүмати-аналитик һәм матди-техник яктан тәэмин итү Бәтке авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.